**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>____________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>_________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>_________Л.П.Шиплянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>233 нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сунгатуллина Флюра Сафуат кызы
9 «А» сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
Утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

**2016 - 2017**

**Укыту предметы үзләштерүнең  планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Сыйныф**: 9 “А”

**УкытучыСунгатуллина Ф С**.

**Уку планы буенча:**

**Барлыгы-**  34 сәг.

**Атнага-**1 сәг

**Программа:** **Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын  коммуникатив технология нигезендә укыту программасы**

**(1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева, 2011 ел.**

**Дәреслек:** **Татар әдәбияты. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек(татар телен өйрәнүче укучылар өчен) ( Авторы: Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Х.Х.Хөснуллина. Казан. “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты.2016 ел.**

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1.Россия Федерациясе Конституциясе 26 ст., 68 бит;

2.Татарстан Республикасы Конституциясе 8 ст.,8 бит;

3. « Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль Законы №273-ФЗ (үзгәрешләр 03.02.2014 , №11-ФЗ, 15-ФЗ);

4. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законы ,8 ст., №68-ЗРТ, 22 июль 2013 ел, 8 бит;

5. «Россия Федерациясенең халыклары телләре турында» Законы, 24.07.98, №126-ФЗ;

6. Россия Федерациясенең милли мәгариф сәясәте концепсиясе, 03.08.2006, №201;

7. «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законы , 08.07.1992 №1560-XII (ред. 03.03.2012)

8.“2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы”

9. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты, Татарстан Республикасы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2008ел

10. “Татарстан Республикасы төп гомуми белем бирү оешмалары өчен төп белем бирү программасының эчтәлеген проектлау буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында”Боерык№2270 19.08.15.

11. Татарстан Республикасы муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең төп гомуми белем бирү программасы.

12. Татарстан Республикасы муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2нче урта гомуми белем мәктәбе” нең 2015- 2016 нчы уку елына укыту планы ( педсовет протоколы, 21 август 2015 ел).

Татар әдәбиятыннан эш программасы бербөтен документ булып тора.Ул түбәндәге өлешләрдән тора: укыту-тематик планлаштыру, аңлатма язуыннан ( төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләрдән) календарь-тематик планнан, укыту – методик комплектыннан( интернет-ресурслар исемлегеннән).

**Уку елы бышына укучыларның гомуми белем һәм күнекмәләренә бәяләмә.**

Сыйныфта татар әдәбияты дәресләрендә уку һәм сөйләм күнекмәләре камилләштерелә.Тәрҗемә итү дә зур урын алып тора.Кайбер укучылар укылган текстларны шунда ук эзлекле рәвештә сөйләп бирәләр.Укучыларның белем дәрәҗәсе төрлечә.Кайбер укучылар белән өстәмә эш алып барыла.

**Сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтүгә таләпләр.**

Тыңлап аңлау. Программада тәкъдим ителгән эчтәлек нигезендә төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү; сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, мәгълүматихарактердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикер әйтү, аралашуга чыгу.

Тыңлап аңлау күнегүләренең вакыт ягыннан яңгырау озынлыгы: 1,2 – 1,5 мин.

Диалогик сөйләм

Программа кысаларындагы тематикада диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү: диалог – сораштыру, диалог – тәкъдим, диалог – фикер алышу, катнаш диалоглар. Диалог күләме: һәр катнашучы ягыннан кимендә 9 – 10 реплика.

Монологик сөйләм. Программада тәкъдим ителгән темалар кысасында сөйләмнең коммуникатив типлары буенча бәйләнешле сөйләмне камилләштерү: сурәтләп сөйләү, эчтәлек сөйләү, хикәя төзү, персонажларны характерлау, хәбәр итү. Монологик сөйләм күләме: кимендә 8 – 10 –12 фраза . Сөйләмнең вакыт ягыннан дәвамлылыгы – 1,5 – 2 мин.

Уку. Программаның предмет эчтәлегенә туры килгән әдәби, фәнни-популяр, рәсми характердагы текстлар белән танышу барышында, мәгълүмат белән эшләү күнекмәләренә ия булу.
Мәгълүматны танып белү, үзләштерү ихтыяҗыннан чыгып, тәкъдим ителгән текстларны аңлап укырга өйрәнү.
Таблицалы текстлар белән эшләү күнекмәләренә ия булу.
Текст укыганда, кирәкле мәгълүматны аерып алу, системага салу, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, интерпретацияләү һәм үзгәртү кебек эшчәнлекләрне үзләштерү.
Текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлау.
Уку өчен текстның күләме: 300 сүзгә кадәр.

**Укыту предметының укыту планында тоткан урыны**
Рус балаларына татар теле һәм әдәбиятын укыту, ана теле һәм әдәбиятын укыту белән беррәттән, аларның филологик белемнәрен киңәйтә һәм коммуникатив культурасын үстерә.Татар теле һәм әдәбиятын укытуга сәгатьләр саны бүленешен, атналык сәгатьләр санын саклаган хәлдә, белем бирү учреждениеләре мөстәкыйль хәл итәләр. Татар теле һәм әдәбият дәресләре бер дәреслек, ике эш программасы нигезендә үзара бәйләнештә, интегратив укытыла.

**Уку предметының эчтәлеге**
Төп гомуми белем бирү мәктәбендә укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен камилләштерү, татар теленнән системалы фәнни белем бирү белән беррәттән, татар дөньясы, татар әдәбияты турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү, ягъни укучыларның комуникатив компетенцияләрен үстерү гомуми максат итеп билгеләнә.

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар әдәбияты укытуның төп максаты һәм бурычлары:
Рус телендә сөйләшүче балалар өчен әдәби уку дәресләре татар язучыларының иң матур әсәрләре белән танышу, аларны дөрес интонация белән, басымнарны урынлы куеп уку, аңлау, истә калдыру, аерым гыйбарәләрне, сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләләрне сөйләмгә кертеп җибәрүгә юнәлдерелергә тиеш. Әдәби текст баланы матур җөмләләр төзеп сөйләргә, татарча аралашуга этәрергә тиеш.
Әдәбият укытуның максаты:
- башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, алар гомумкешелек әхлакый сыйфатларын тәрбияли алырдай әсәрләр аша укучыларның татар телен өйрәнүгә кызыксынуларын, ягъни уку мотивациясен көчәйтү;
- рус телендә сөйләшүче балаларны татар әдәбиятының алтын хәзинәсен тәшкил иткән әдәби әсәрләр белән таныштыру;
- татар халкының тарихына, мәдәниятына ихтирам хисе тәрбияләү;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү аша, укучыларның татар телендә телдән һәм язмача аралашу мөмкинлекләрен киңәйтү;
<u>Төп эшчәнлек төрләре</u>
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлау һәм иҗади уку;
- сәнгатьле уку, кабатлау сөйләүнең төрләре;
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- укыган әдәби текстның идеясен, автор позициясен, геройларның теге яки бу гамәленә нигез булган мотивларны һәм конфликтның асылын ачыклау;
- бәхәсләрдә катнашу, авторларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын раслау һәм дәлилләү;
- рус һәм татар телендәге әсәрләрне чагыштырып бәяләү;
- рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү
<u>Контроль төрләре.</u>
Укучыларга татар теленнән системалы белем бирү өчен түбәндәге контроль төрләре кулланыла:

контроль эшләр, мөстәкыйль биремнәр, тестлар, карточкалар белән эш,ситуатив күнегүләр һ.б. Арадаш аттестация үткәрү өчен проект эше сайланды, чөнки бу эш программада тәкъдим ителгән темалар кысасында сөйләмнең коммуникатив типлары буенча бәйләнешле сөйләмне тикшерә ала.

Әдәбият укыту буенча эш программасы түбәндәге сөйләм эшчәнлеге төрләренә нигезләнә:

- диалогик сөйләм (парлап яки күмәк сөйләшү барышында, үз фикереңне аңлата, раслый, иллюстрацияләр кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү).
- монологик сөйләм (сораулар ярдәмендә, план буенча яисә мөстәкыйль рәвештә өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләү, өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйләү, персонажларны тасвирлау).
- тыңлап аңлау (тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау җөмләләр төзү, сорауларга җавап бирү,аралашу барышындачит сөйләмне ишетеп аңлау, зур булмаган текстларны аудиоязмада тыңлап аңлау, сүзләрне, җөмләләрне тыңлапаңлап тәрҗемә итү).
- уку (программада тәкъдим ителгән әдәби әсәрләрне, әсәрләрдән өзекләрне, автор текстларын, орфоэпик нормаларны саклап, сәнгатьле уку, зур булмаган текстларны үзлектән аңлап уку,тәкъдим ителгән әдәби әсәрләрне сүзлек кулланып уку, таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен билгеләү, таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән табу,текстны микротекстларга бүлеп уку, исем кую).
- язу (программага кертелгән сүзләрне дөрес язу, вакыйганы хикәяләп, картинаны сурәтләп язу, конкрет бер тема буенча хикәя төзеп язу).

Татар әдәбияты буенча эш программасы укучыларныңкоммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләрен булдыруга юнәлтә, коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белүне алгы планга куя.

Урта баскычта рус телле балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү**.** Урта баскычта татар халкының рухи дөньясын чагылдырган, тормыш – көнкүрештәге әхләкый проблемаларны үз эченә алган, укучыларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры килгән әдәби әсәрләр белән танышу; укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты.

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне устерү.

Программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алырга кирәк. Эчтәлектә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясен булдыру мөһимнәрдән санала.

| № | Дәрес темасы | Укыту эшчәнлеге | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| **Атадан улына чын мирас-сүздер- 3 сәг.** | | | |
| 1 | Халык авыз иҗаты. Дастаннар.”Идегәй” дастаны. “Идегәй” дастаны турында. | Тарихка кыскача күзәтү | **2.09** |
| 2 | “Идегәй” трагедиясе. Идегәй” трагедисе турында | Текстны анализлау | **9.09** |
| 3 | Кол Гали. “Кыйссаи Йосыф” | Текст белән танышу | **16.09** |
| **Мәхәббәт бер булса да, ике йөрәктә яши-4 сәг.** | | | |
| 4 | Сәйф Сараи. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаны | Текст өстендә эш | **23.09** |
| 5 | С.Сараи “Сөһәйл вә Гөлдерсен”дастаны турында. | Тәрҗемә итү алымнары | **30.09** |
| 6 | Сайади. “Таһир –Зөһрә” | Парларда эшләү | **7.10** |
| 7 | “Таһир  белән Зөһрә кыйссасы” | Текстка анализ ясау | **14.10** |
| **Гөл үссә- җирнең күрке, кыз үссә-илнең күрке-6 сәг.** | | | |
| 8 | Габделҗаббар Кандалый.”Сәхибҗамалга” | Әсәр өстендә эш | **21.10** |
| 9 | Ризаэтдин Фәхретдин. “Әсма, яки Гамәл вә җәза” | Тәрҗемә итү өстендә эш | |
| 10 | Г.Тукай. “Татар кызларына”. Г.Тукай музее | Монолог төзү | **28.10** |
| 11 | Фатих Әмирхан. “Хәят” | Парларда эшләү | **11.11** |
| 12 | Аяз Гыйләҗев. “Җомга көн, кич белән...” | Текст өстендә эш | **18.11** |
| 13 | Рөстәм Мингалим. “Сап-сары көзләр”. “Кышкы суыкларга кердек исә”, “Күңелемдә менә шундый шатлык бар”, “Бәхетем” | Сәнгатьлелек өстендә эш | **25.11** |
| **Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне юата-5 сәг** | | | |
| 14 | Лирика.Пейзаж лирикасы. Ркаил Зәйдулла “Буран”,Илсөяр Иксанова “Тузганак” | Лирик геройны характерлау | **2.12** |
| 15 | Гражданлык лирикасы. Сания Әхмәтҗанова “Татар акылы”, “Сүнмәс балкыш” | Тәрҗемә итү алымнарын куллану | **9.12** |
| 16 | Сәяси лирика.Фәлсәфи лирика.М.Шабаев”Корылган имән монологы”, Мөхәммәт Мирза “Робагыйлар”, “Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына...” | монологтөзү | **16.12** |
| 17 | Күңел лирикасы. Ф.Җамалетдинова “Ташлар”, “Кунак көткән кебек”. | Текстны анализлау | **23.12** |
| 18 | Р.Әхмәтҗанов “Сандугач керде күңелгә” | Лирик геройны характерлау | **14.01** |
| **Театр-яктылыкка,нурга илтә!-4 сәг.** | | | |
| 19 | Галиәсгар Камал. “Беренче театр” | сәхнәләштерү | **21.01** |
| 20 | “Сәйар”труппасы. С.Гыйззәтуллина-Волжская | Текст өстендә эш | **28.01** |
| 21 | Канәфи Нәфыйков. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. | Проект эше | **3.02** |
| 22 | Х.Мөдәррисова “Бәйге хакы”. Казан театр училищесы. | Проект эше | **10.02** |
| **Мең шифага ия кулларда күпме язмышлар эзе бар...-2сәг.** | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23 | Г.Әпсәләмов “Ак чәчәкләр”. С.Сөләйманова “Дөнья бу...” | Парларда эшләү | **16.02** |
| 24 | Казан медицина колледжы.А.Расих “Тәҗрибә” | Төркемнәрдә эшләү | **24.02** |
| **Укытучым! Синең бөек исемең йөрәгемдә мәңге сакланыр...** | | | |
| 25 | М.Мәһдиев “Фронтовиклар” | Тәрҗемә итү алымнары | **3.03** |
| 26 | Казан педагогия колледжлары. Р.Гаташ “Укытучы”, Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”. М.Галиев | Текстларга анализ бирү | **10.03** |
| 27 | Л.Шагыйрьҗан “Укытучы”.В.Нуриев “Инша”. “Идел”журналы | Сорауларга җавап бирү | **17.03** |
| **Авыр эшкә беләк бар,кыю эшкә йөрәк бар.-8сәг** | | | |
| 28 | Х.Сәрьян “Әткәм һөнәре”. Г.Ахунов “Хәзинә”романы. | Текстны анализлау | 7.04 |
| 29 | И.Юзев “Таныш моңнар”. Х.Камалов “Очучы” | Парларда эшләү | 14.04 |
| 30 | Н.Әхмәдиев “Авылдашым”. М.Маликова”Казан каласы-таш кала”. | Тәрҗемә итү | 20.04 |
| 31 | Еллык контроль тест | Тест башкару | 29.04 |
| 32 | С.Гәрәева “Токарь”.Казан политехник колледжы. | Текст өстендә эш | 5.05 |
| 33 | Йомгаклап кабатлау | | 10.05 |